**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**“Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре, мәйдан Советы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**“Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

# Арча шәһәр Советы
# КАРАРЫ

**« 11 » сентябрь 2024 ел** **№ 132**

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Арча шәһәр Советының 2021елның 27 апрелендәге 30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге уставына (17.12.2021 №55, 30.09.2022 №83, 23.10.2023 №109 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 6 статьяның 1 өлешендә:

а) 31 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру»;

б) 32 пунктчада «, шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләреннән» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 41 пунктча өстәргә:

«41) муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 42 пункт өстәргә:

«42) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру;».

2) 8 статьяның 2 өлешендә «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

3) 13 статьяның 7 пунктында «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

4) 15 статьяда:

а) 5 пунктта «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Территориаль комиссия инициатив төркем үтенечнамәсен караганда, җирлек Советы җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү билгеләгәндә, җирлек Советының әлеге депутаты аны чакыртып алу өчен нигез буларак күрсәтелә торган хәлләр турында аңлатмалар бирергә, кирәкле документларны тапшырырга хокуклы. Әлеге депутатка территориаль комиссия, җирлек Советы утырышларын уздыру көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча алдан ук, аларны уздыру вакыты һәм урыны турында язмача хәбәр ителергә тиеш.»;

в) 12 пунктта «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль комиссия» сүзләренә алмаштырырга»;

5) 19.1 статьяның 5 пунктының икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1-7 һәм 9.2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

6) 25 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган очракларда гражданнар җыены уздырылырга мөмкин:

1) составына күрсәтелгән торак пункт кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча торак пунктта күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүгә китерә торган җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

2) җирлек составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;

3) торак пунктта авыл старостасы кандидатурасын күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

4) торак пунктта гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздырганда, муниципаль хезмәт турындагы

Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында уздырылырга мөмкин.

Гражданнар җыены торак пункт территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча уздырылырга мөмкин.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре, җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл итүдә торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләре уртаклыгы критериеннан чыгып, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.».;

7) 33 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы шәһәр Советы депутаты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш), күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре) Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесенә) Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алдан хәбәр итеп;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре Советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә чагылдыру;

г) гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләргә (устав капиталындагы өлешләргә) идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә чагылдыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни

һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

4) Әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтчелек советлары, коммерциячел булмаган чит ил хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә эш итүче аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керергә.

Вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат граждан, административ яисә җинаять эше яки административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яисә вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) сыйфатында катнаша алмый.

Шәһәр Советы депутатларының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре әлеге устав белән федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.»;

8) 36 статьяда:

а) 1 өлешнең 17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 1 өлешнең 32 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

9) 43 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11.1 пункт өстәргә:

«11.1) аның чит ил агенты статусын алуы;

10) 46 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлек башлыгы түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш), күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре) Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма

органы җитәкчесенә) Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алдан хәбәр итеп;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре Советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә чагылдыру;

г) гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләргә (устав капиталындагы өлешләргә) идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә чагылдыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

4) Әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтчелек советлары, коммерциягә карамаган чит ил хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә эш итүче аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керергә.»;

б) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларның счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, бурычлар үтәлмәгән очракта, аларның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла, әгәр әлеге Федераль законда башкасы каралмаган булса».

11) 52 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пунктындагы унынчы абзацында «, шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләреннән» сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлешнең 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала»;

в) 1 өлешнең 7 пунктындагы өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) 1 өлешнең 9 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

д) 3 өлештә «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга.;

12) 60 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«60 52 статья. Җирлекнең ревизия комиссиясе

«1. Ревизия комиссиясе - җирлек бюджеты үтәлешен, бюджет проектын, аның үтәлеше турындагы хисапны әзерләүнең һәм карауның билгеләнгән тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны, шулай ук муниципаль милектәге мөлкәт белән идарә итүнең һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибе үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыра торган контроль-хисап органы.

2. Җирлекнең ревизия комиссиясе җирлек Советы тарафыннан төзелә һәм аның контролендә була.

3. Җирлекнең ревизия комиссиясе рәистән һәм ике әгъзадан тора.

Ревизия комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе, вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, җирлекнең ревизия комиссиясе турында җирлек Советы раслаган нигезләмә, башка муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

4. Федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә җирлекнең ревизия комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлеген хокукый җайга салу шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.»;

13) 61 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

14) 71 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) аның чит ил агенты статусын алуы.»;

15) 76 статьяның 2 өлешендәге 17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

16) 77 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «Башкарма комитет җитәкчесе карарларын һәм күрсәтмәләрен» сүзләрен «Башкарма комитет карарларын һәм күрсәтмәләрен» сүзләренә алмаштырырга;

17) 82 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«82 статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көченә керү тәртибе»

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар халыкка рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып түбәндәгеләр тора:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык ЭЛ№ФС77-60244 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан (Роскомнадзор) 17.12.2013 бирелгән яисә «Арча хәбәрләре» («Арчский вестник») Арча район газетасында (массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык ЭЛ № ФС77–47527 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан 30.11.2011 бирелгән) рәсми бастырып чыгару;

2) Арча муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru), ТР, Арча МР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 25 йорт; Арча шәһәре, Һ.Такташ урамы, 58 йорт; Арча шәһәре, Кленовая урамы, 4 йорт; Арча шәһәре, Банковская урамы, 2а йорт адреслары буенча мәгълүмати стендларда урнаштыру;

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли: ТР, Арча МР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 7 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Арча шәһәр Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга кул куелган көннән үз көченә керә.

7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмаларының, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмаларының, челтәр басмаларының исемлеге Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерелә.

8. статьяда «Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм ТР, Арча МР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 25 йорт; Арча шәһәре, Һ.Такташ урамы, 58 йорт; Арча шәһәре, Кленовая урамы, 4 йорт; Арча шәһәре, Банковская урамы, 2а йорт адреслары буенча мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе

«Совет города Арск»

И.Г. Нуриев